ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» февраля 2024 ел № 25

«2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.04.2023 елның 77 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2019-2025 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.03.2019 елның 159 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 24.11.2020 елның 3081-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясе нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 06.04.2023 елның 77 номерлы карары белән расланган «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 нчы бүлек. Әгерҗе муниципаль районында 2023-2025 елларга Физик культура һәм спортны үстерү буенча чараларны 5.6, 6.3, 6.6, 6.7 пунктлары белән тулыландырырга.

| **№** | **Чараларның эчтәлеге** | **Башкару вакыты** | **Башкару өчен җаваплы** | **Финанслау күләме (мең сум)** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2023** | **2024** | **2025** |
| 5.6 | Спорт мәктәпләрен җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 2023-2025еллар | ТР ӘМР "Спорт мәктәбе" ӨББ МБУ | 128,12 | 115,78 | 0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтмәсе нигезендә бюджетара трансфертлар. (республика бюджеты) | | | | | |
| 6.3 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә спорт мәктәпләренә спорт әзерләү программаларын гамәлгә ашыруга һәм хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында (республика бюджеты) спорт командаларының катнашуына бюджетара трансфертлар | 2023-2025еллар | ТР ӘМР «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ | 399,0 | 0 | 399,0 |
| 6.6 | Спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе белән расланган бюджетара трансфертлар | 2023-2025еллар | ТР ӘМР «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ | 2,8 | 40,0 | 0 |
| 6.7 | «Татарстан Республикасы бюджетыннан югары квалификацияле спортчылар, шулай ук спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен тренерлар-укытучыларга, шулай ук спортчыларга - инструкторларга һәм спортчыларга бүләкләүләр түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.12.2018 елның 1258 номерлы карары | 2023-2025еллар | ТР ӘМР «Спорт мәктәбе» ӨББ МБУ | 100,0 | 100,0 | 0 |

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «Физик культура һәм спорт» тармаклары буенча каралган бюджет чаралары кысаларында муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга бюджет акчалары бүлеп бирүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Г.Ф. Җәметовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**